| | |
|---|---|
| ГЛАВА УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь, 2021 ел Ульянково ав. № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең Ульянково авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 22 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Ульянково авылы, Мәктәп урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан Ульянково мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның беренче этабың билгеләргә.
2. 2021 елның 24 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Ульянково авылы, Елга буе урамы адресы буенча урнашкан ООО “Август-Кайбыч”ның ҖЧҖнең терлекчеләр йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның икенче этабын билгеләргә.
3. 2021 елның 24 ноябренә 11 сәгать 30 минутка Ульянково авылы, Яшел урамы, 25 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның өченче этабын билгеләргә.
4. 2021 елның 26 ноябренә 14 сәгать 30 минутка Ульянково авылы, 34а йорт адресы буенча урнашкан Ульянково төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның дүртенче этабын билгеләргә.

5. 2021 елның 26 ноябренә 18 сәгать 30 минутка Ульянково авылы, Мәктәп урамы, 39 нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл жирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар жыенын бишенче этабын билгеләргә.
6. 2021 елның 29 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Ульянково авылы, Зур урамы, 18 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл жирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар жыенын алтынчы этабын билгеләргә.
7. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл жирлегене Ульянково авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре;
- жирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: кирәкле материаллар сатып алып янгын сүндерү депосы төзү, янгын сүндерү машинасын карап тоту;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны Ульянково авыл жирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл жирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
9. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл жирлеге башкарма комитеты гражданнар жыенын үткәргәндә Ульянково авыл жирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) авыруы очракларын кисәтү һәм тарату өчен профилактик, санитар-эпидемияләргә каршы чараларны үтәүне тәэмин итәргә.
10. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Ульянково авыл жирлеге башлыгы** **Ф.А. Сундурова**